ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44 E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**2019 ел** «06» декабрь **№** 1080

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Арча муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәткә түләү шартлары турында» 2018 елның 11 июлендәге 598 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Арча муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәткә түләү шартлары турында» 2018 елның 11 июлендәге 598 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәткә түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

1 бүлекнең 3 пунктындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә мәшгуль хезмәткәрләрнең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба – мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре) хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:»;

II бүлекнең 1 пункты таблицасындагы 5 графада «кече тәрбияче» юлындагы «10 020» санын төшереп калдырырга;

II бүлекнең 2 пункты таблицасындагы "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме" бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| " Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме" | | |
|---|---|---|
| Китапханәче | 10 500 | 13 000»; |
| Тавыш операторы | | |
| Әйдәп баручы китапханәче | | |
| Рәссам-декоратор | | |
| Баш китапханәче | | |

III бүлектә:

1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакытының озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгате нормасы) атнага 36 сәгатьтән артмаган эш вакытының кыскартылган озынлыгыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә укыту (уку-укыту), тәрбия бирү эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфасына караган бурычлар һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне үз эченә ала»;

3.1 пунктчаның сигезенче абзацында «рус булмаган» сүзен төшереп калдырырга;

3.6 пунктчаның тугызынчы абзацында «15» санын «20 » санына алмаштырырга»;

V бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Язма эшләрне тикшерү өчен түләүләр (дәфтәрләрне тикшерү) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B^{pr}_{nz} = \left( \sum O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{pr},$$

биредә:

$B^{pr}_{nz}$ – язма эшләрне тикшерү өчен түләү күләме (дәфтәрләрне тикшерү);

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәренең база оклады күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмасында предмет буенча алып барылган педагогик эшнең факттагы сәгать саны;

$Y_f$ – гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең факттагы саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакы база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$ – гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P-китап бастыру продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаган күләмдә билгеләнә;

$D_{ТД}$- 1 нче таблицада китерелгән язма эшләр тикшерү (дәфтәр тикшерү) өчен өстәмә күләме;

V бүлектәге 2 пунктның сигезенче абзацында «300» санын «550» санына алмаштырырга»;

VI бүлектә:

1 пунктның 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

квалификация категориясе өчен түләүләр;

белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр;

дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

хезмәт нәтиҗәлелеге өчен түләүләр;

премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;

башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр»;

3 таблицаның 9 пунктындагы 3 графасын «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң "һәм төп вазыйфа" сүзләрен өстәргә»;

түбәндәге эчтәлекле 5.8 пунктча өстәргә:

«5.8. Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{er} = \left( O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{er},$$

биредә:

$B_{ер}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен түләү;

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәренең база оклады күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмасында предмет буенча алып барылган педагогик эшнең факттагы сәгать саны;

$Y_f$- гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләре тарафыннан факттагы хезмәт күрсәтү саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакы база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$-гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәрләре күрсәтә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P-китап бастыру продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаган күләмдә билгеләнә;

Dsr- хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү 28 процент күләмендә билгеләнә.»;

14 пунктны «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа" сүзләрен өстәргә»;

15 пунктта:

«белем бирү» сүзен «гомуми белем бирү» сүзенә алмаштырырга, "һәм төп вазыйфаны" сүзләрен төшереп калдырырга.

15.2 пунктчада "белем бирү" сүзен «гомуми белем бирү» сүзенә алмаштырырга;

15.3 пунктчасындагы тугызынчы абзацта «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

15.11 пунктчасындагы бишенче абзацта «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүгә хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителгән күләме төп эш урыны һәм төп вазыйфасы (укытучылар һәм педагог укытучылар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) буенча гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча хезмәт хакы түләү фондының 16 проценты күләмендә кабул ителә.»;

9 пунктта 3 таблицаның 2 графасында «(«башлангыч мәктәп - балалар бакчасы», «прогимназия» статусларыннан тыш)" сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Россия Федерациясенең дәүләт бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Совет Социалистик Республикалар берлеге составындагы союздаш һәм автоном республикалар һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр беренче һәм икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал, педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times Dpz$$

биредә:

$B_{pz}$-дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү;

$O_d$-гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$Д_{пз}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Россия Федерациясенең дәүләт бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Совет Социалистик Республикалар берлеге составындагы союздаш республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре (Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы) булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Совет Социалистик Республикалар берлеге составында союздаш республикаларның тармак бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе Мактау грамотасы белән бүләкләнгән мәгариф хезмәткәрләренә өстәмә түләү Россия Федерациясенең Мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе мәгариф министры) боерыгы белән, Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре тапшыру Тәртибе нигезендә билгеләнә.

"Мәгарифтәге казанышлары өчен" Татарстан Республикасының күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. "Мәгарифтәге казанышлары өчен" Татарстан Республикасының күкрәк билгесенә ия булган өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелгән»;

түбәндәге эчтәлектәге 8.2 пунктны өстәргә:

«8.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

биредә:

$B_{sd}$- эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү;

$O_d$ - гомуми белем бирү оешмаларында мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$- эшчәнлек үзенчәлеге өчен кабул ителгән 9 процентка тигез өстәмә түләү »;

13пунктта:

беренче, дүртенче, алтынчы абзацларда һәм 11 нче таблицаның атамасында "эш катлаулылыгы" сүзләрен "хезмәт интенсивлыгы" сүзләренә алмаштырырга»;

VI бүлектәге 13 нче таблицаның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.3-2.5 пунктчаларын өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. | Әйдәп баручы китапханәче | 42 |
| 2.4. | Рәссам-декоратор | 45 |
| 2.5. | Баш китапханәче | 45»; |

VII бүлектә:

3 пунктның беренче абзацында "структур бүлекчәләр җитәкчеләре" сүзләреннән соң «мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган мәдәният хезмәткәрләренә, урта, әйдәп баручы звено һәм җитәкче состав хезмәткәрләренә, урта медицина һәм фармацевтика персоналының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче медицина хезмәткәрләренә, табибларга һәм провизорларга" сүзләрен өстәргә»;

15 таблицаның 9 пункты 2 графасында "интеллект бозылу" сүзләрен "психик үсеш тоткарлануы, аутистик үсеш бозылулары, катлаулы дефектлы һәм акылга зәгыйфь балалары белән" сүзләренә алмаштырырга»;

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

$$"B_{kh} = O_b \times D_{kh} \times \frac{H_{lk}}{H_N}";$$

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәренең база оклады күләме;

9 пунктның 15 таблицасына түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «12. | Үсештә тайпылышлар булган укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә әйдәп баручы звено хезмәткәрләре вазыйфалары | - | 4.5»; |

VIII бүлекнең 16 таблицасында:

б) 2 нче графа атамасын түбәндәге редакциядә бирергә:

"Күләмле күрсәткеч мәгънәсе (укучылар, тәрбияләнүчеләр саны уку елы башына), кеше <*>»;

сносканы түбәндәге редакциядә бирергә:

«<*> Гомуми белем бирү оешмаларының ябык типтагы девиант тәртипле укучылар контингенты, җинаять-башкарма системасының төзәтү учреждениеләре каршындагы гомуми белем бирү оешмалары, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмалары, җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмалары өчен 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмалары интернатларында яшәүче укучылар контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпкә алына.

«Мәктәпара уку комбинатларында укучылар контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына.»;

күрсәтелгән Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

"Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалары берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре булган өчен бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләүләре" бүлегендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»;

түбәндәге эчтәлектәге 1.8, 1.9 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| "1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре»; |

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| 2.5. | "Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы " билгесе»; |

Әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

III бүлектә:

1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакытының озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгате нормасы) атнага 36 сәгатьтән артмаган эш вакытының кыскартылган озынлыгыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә укыту (уку-укыту), тәрбия бирү эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфасына караган бурычлар һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне үз эченә ала»;

3.2 пунктның тугызынчы абзацында «15» санын «20» санына алмаштырырга»;

V бүлектә:

1 пунктның 1.1 пунктчасындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

"хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар берлегенең, Совет Социалистик Республикалар берлеге составындагы союздаш һәм автоном республикаларның һәм Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр беренче һәм икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал, педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$_{Bpz} = _{Od} \times Dpz,$$

биредә:

$_{Bpz}$-дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$_{Од}$-мәктәпкәчә белем бирү оешмасында мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$_{Дпз}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Социалистик Республикалары берлеге составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре (Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы) булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Совет Социалистик Республикалар берлеге составында союздаш республикаларның тармак бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе Мактау грамотасы белән бүләкләнгән мәгариф хезмәткәрләренә өстәмә түләү Россия Федерациясенең Мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия

Федерациясе мәгариф министры) боерыгы белән Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре тапшыру Тәртибе нигезендә билгеләнә.

"Мәгарифтәге казанышлары өчен" Татарстан Республикасының күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. "Мәгарифтәге казанышлары өчен" Татарстан Республикасының күкрәк билгесенә ия булу өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт һәм тармак бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелгән.»;

6 пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$"B_{st} = \left( O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{st},";$$

дүртенче, алтынчы абзацларда «эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге» сүзләрен «хезмәт интенсивлыгы" сүзләренә алмаштырырга»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Р-китап бастыру продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаган күләмдә билгеләнә»;

11 пунктта:

беренче, дүртенче, алтынчы абзацларда һәм 8 таблицаның атамасында «эшнең катлаулылыгы» сүзләрен «хезмәт интенсивлыгы" сүзләренә алмаштырырга»;

12 пунктта «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктта «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа" сүзләрен өстәргә»;

VI бүлектә:

1 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

"нормадан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, дәрестән тыш эш башкарганда, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылышучы башка шартларда) эшләрне башкарган өчен түләүләр");»;

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

$$"B_{kh} = O_b \times D_{kh} \times \frac{H_{\&}}{H_N}";$$

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

"Ob – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәренең база оклады күләме;

6 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

11 таблицаның 1 пунктының 2 графасында «тәрбияләнүчеләр өчен» сүзләреннән соң «туберкулез интоксикациясе белән" сүзләрен өстәргә,»;

8 пунктның беренче абзацында «мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында» сүзләреннән соң «җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы" сүзләрен өстәргә»;

3 пунктның беренче абзацында «структур бүлекчәләр җитәкчеләре» сүзләреннән соң «урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар профессиональ квалификация төркемнәренә керүче медицина хезмәткәрләренә" сүзләрен өстәргә»;

11 таблицаның 1 пункты 2 графасында "интеллект бозылу" сүзләрен "психик үсеш тоткарлануы, аутистик үсеш бозылулары, катлаулы дефектлы һәм акылга зәгыйфь балалары белән" сүзләренә алмаштырырга»;

VII кисәкнең 12 таблицасына сносканы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<*>Җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.»;

күрсәтелгән Нигезләмәгә № 1 кушымтада:

«Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре" бүлегендә»:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»;

түбәндәге эчтәлектәге 1.8, 1.9 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| 1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре»; |

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| | "Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы" |

| | |
|---|---|
| 2.5. | билгесе; |

Әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

III бүлекнең 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Өстәмә белем бирү бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакытының озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгате нормасы) атнага 36 сәгатьтән артмаган эш вакытының кыскартылган озынлыгыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә укыту (уку-укыту), тәрбия бирү эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфасына караган бурычлар һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне үз эченә ала»;

V бүлектәге 4 пунктның беренче абзацында «5.1 һәм 5.2 пунктлары белән билгеләнгән» сүзләрен «V бүлекнең 1-3 пунктлары белән билгеләнгән" сүзләренә алмаштырырга;»;

VI бүлектә:

1 пунктның 1.1 пунктчасындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

"хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;»;

2.5 пунктчаның унынчы абзацында "Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе мәгариф министры)" сүзләрен "Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе Мәгариф Министры)" сүзләренә, "Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)" сүзләрен "Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгы)" сүзләренә алмаштырырга;)";

беренче, дүртенче, алтынчы абзацларда һәм 16 таблицаның атамасында «эш катлаулылыгы» сүзләрен «хезмәт интенсивлыгы" сүзләренә алмаштырырга»;

7 пунктта "гомуми белем бирү оешмалары» сүзләрен "өстәмә белем бирү оешмалары" сүзләренә алмаштырырга»;

7.2 пунктчада «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләрен "өстәмә белем бирү оешмалары" сүзләренә алмаштырырга»;

7 пунктта «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа" сүзләрен өстәргә»;

8 пунктта « һәм төп вазыйфа » сүзләрен төшереп калдырырга;

VII бүлектә:

8 пунктта «кимендә» сүзен төшереп калдырырга;

VIII бүлектә:

5 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

"өстәмә белем бирү оешмаларында җитәкчегә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр 28 нче таблицада бирелгән.»;

өченче абзацта «кызыксындыру характерындагы» сүзләреннән соң «башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен" сүзләрен өстәргә»;

6 пунктта:

икенче җөмләдә «кызыксындыру характерындагы түләүләр» сүзләреннән соң «башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен" сүзләрен өстәргә»;

3 җөмләне түбәндәге редакциядә бирергә:

«Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләренең 70 процентына кадәр билгеләнә.»;

28 таблицаның атамасында һәм 4 графасы исемендә «кызыксындыру характерындагы" сүзләреннән соң "башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен» сүзләрен өстәргә»;

8 пунктта:

беренче абзацта «Сыйфат өчен түләүләр» сүзләрен «Сыйфат өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр" сүзләренә алмаштырырга»;

бишенче абзацта «кызыксындыру характерындагы» сүзләреннән соң «башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен" сүзләрен өстәргә»;

күрсәтелгән Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның таблицасында:

«Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасынын, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре" бүлегендә»:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»;

түбәндәге эчтәлектәге 1.9, 1.10 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| "1.9. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре»; |

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| 2.6. | “Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы" билгесе»; |

Әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районы һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

II бүлектәге 3 пунктның таблицасында 5 графада «15 200" санын "17 000» санына алмаштырырга»;

II кисәкнең 1 пункты таблицасында:

"Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме" бүлегендәге "Дүртенче квалификация дәрәҗәсе" юлына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | "Педагог-китапханәче <*> | - | - | 14 236»; |

түбәндәге эчтәлекле сноскалар өстәргә:

"<*> Арча муниципаль районының төп гомуми белем бирү программаларын һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль һөнәри белем бирү оешмалары өчен.»;

III бүлектә:

1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакытының озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгате нормасы) атнага 36 сәгатьтән артмаган эш вакытының кыскартылган озынлыгыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә укыту (уку-укыту), тәрбия бирү эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфасына караган бурычлар һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне үз эченә ала»;

2.1 пунктчасында:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«һөнәри белем бирү оешмалары өчен барлык һөнәрләр буенча практик дәресләр үткәргәндә-12-15 кеше, катлаулы җиһазларга хезмәт күрсәтү, куркыныч эшләр башкару белән бәйле һөнәрләр буенча - 8-10 кеше.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Чит тел, туган тел һәм әдәбият, рус теле һәм әдәбияты буенча дәресләрне туган телдә укытучы һөнәри белем бирү оешмаларында, информатика һәм исәпләү техникасы, физика һәм химия буенча дәресләрне (гамәли дәресләр вакытында) төркемне ике төркемчәгә бүлү рөхсәт ителә: шәһәр һөнәри белем бирү оешмаларында, төркемнең тулылыгы 25 кеше булса, авыллардагы оешмаларда - 20дән ким булмаган кеше.»;

5.13 пунктчада «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы" сүзләренә алмаштырырга.

күрсәтелгән Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 1 нче таблицасына түбәндәге эчтәлекле 3.23 пункты белән өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3.23. | Педагог-китапханәче | дүртенче | 60»; |

V бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Язма эшләрне тикшерү өчен түләүләр (дәфтәрләрне тикшерү) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B^{pt}_{nt} = \left( \sum O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{pt},$$

биредә:

$B^{pt}_{nt}$ – язма эшләрне тикшерү өчен түләү күләме (дәфтәрләрне тикшерү);

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган һөнәри белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәренең база оклады күләме;

$H_f$ – һөнәри белем бирү оешмасында предмет буенча алып барылган педагогик эшнең факттагы сәгать саны;

$Y_f$-һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең факттагы саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән һөнәри белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакы база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$-һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре күрсәтә торган хезмәтләрнең норматив саны;

Р-китап бастыру продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаган күләмдә билгеләнә;

$D_{pt}$- 1таблицада китерелгән язма эшләр тикшерү (дәфтәр тикшерү) өчен өстәмә түләү күләме;

VI бүлектә:

1 пунктның 1.1 пунктчасындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

"хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр»;

2.5 пунктчаның унынчы абзацында "Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе мәгариф министры)" сүзләрен "Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе Мәгариф Министры)" сүзләренә, "Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)" сүзләрен "Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгы)" сүзләренә алмаштырырга;)";

4 пунктның 4.5 пунктчасында:

беренче, дүртенче, алтынчы абзацларда һәм 10 таблицаның атамасында «эш катлаулылыгы» сүзләрен «хезмәт интенсивлыгы" сүзләренә алмаштырырга»;

6 пунктта «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа" сүзләрен өстәргә»

6 пунктның 6.2 пунктчасында «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмалары" сүзләренә алмаштырырга»;

7.1 пунктта «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

VII бүлектәге 1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

"нормадан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, дәрестән тыш эш башкарганда, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылышучы башка шартларда) эшләрне башкарган өчен түләүләр ");»;

6 пунктта «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа" сүзләрен өстәргә»;

күрсәтелгән Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасында:

«Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре" бүлегендә»:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»;

түбәндәге эчтәлектәге 1.8, 1.9 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| 1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясе балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре"; |

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| 2.5. | "Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы" билгесе»; |

Әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районы мәгариф оешмалары гомумтармак һөнәрләре житәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре, эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, гомумтармак вазыйфалары белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәнең II бүлегендәге 3 пунктта "Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы" сүзләрен "Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы" сүзләренә алмаштырырга.

V бүлектәге 2 пунктның 2.1 пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

$$"B_{kh} = O \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_N}, ";$$

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

"О - Арча муниципаль районы мәгариф оешмалары гомумтармак һөнәрләре җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре, эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, гомумтармак вазыйфалары белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база окладлары күләме;".

3 пунктның алтынчы абзацында "кимендә" сүзен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И.Гарифжановка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә. Галимуллин